КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 гыйнвар г.Казань № 74

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларында тикшерүдә тоту (күзәтчелек) эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планын («юл картасы»н) раслау турында» 2017 ел, 28 февраль, 121 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 20 гыйнвар, 14 нче; 2020 ел, 25 сентябрь, 867 нче; 2020 ел, 1 декабрь, 1081 нче; 2021 ел, 26 февраль, 104 нче; 2021 ел, 16 агуст, 723 нче; 2021 ел, 23 октябрь, 1000 нче; 2022 ел, 19 май, 473 нче; 2022 ел, 28 октябрь, 1148 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Россия Федерациясе субъектларында тикшерүдә тоту (күзәтчелек) эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планына («юл картасы»на) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең дүртенче абзацында «28 төр» сүзләрен «29 төр» сүзләренә алмаштырырга;

III бүлекнең 5 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «5 бүлек. Татарстан Республикасында контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү | | | | |
| 5.1. | Татарстан Республикасында контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген камилләштерүгә юнәлдерелгән мәгълүмати карарларны (ресурсларны) кертү | «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – «ККЭ ББЧ» ДМС) администраторлаштыру, әлеге дәүләт мәгълүмат | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашы- |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | системасында эшләгәндә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген), Россия Федерациясе субъектларына гамәлгә ашыру вәкаләтләре тапшырылган федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы контроль (күзәтчелек) органнарына консультация ярдәме күрсәтү | | ручы контроль (күзәтчелек) органнары, Россия Федерациясе субъектларына вәкаләтләре тапшырылган федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы контроль (күзәтчелек) органнары |
| 5.2. | Федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге), төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төрләренең бердәм реестрында (алга таба – Контроль төрләренең бердәм реестры) мәгълүмат урнаштыру һәм аларны актуальләштерү | Контроль төрләренең бердәм реестрында урнаштырылган дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында актуаль һәм тулы мәгълүмат | дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны җайга сала торган норматив хокукый актлар үз көченә кергән көннән биш көн эчендә | төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы контроль (күзәтчелек) органнары, Россия Федерациясе субъектларына гамәлгә ашыру вәкаләтләре тапшырылган федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы контроль (күзәтчелек) органнары |
| 5.3. | «ККЭ ББЧ» ДМСна планлаштырыла һәм үткәрелә торган профилактик чаралар турында мәгълүмат кертү, контроль (күзәтчелек) чаралары статусын үз вакытында үзгәртү | «ККЭ ББЧ» ДМСна планлаштырыла һәм үткәрелә торган профилактик чаралар турында мәгълүмат кертү – 100 процент, контроль (күзәтчелек) чаралары статусын үз вакытында үзгәртү | ай саен | төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы контроль (күзәтчелек) органнары, Россия Федерациясе субъектларына гамәлгә ашыру вәкаләтләре тапшырылган федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы контроль (күзәтчелек) органнары |
| 5.4. | «ККЭ ББЧ» ДМСна планлаштырыла һәм үткәрелә торган профилактик чаралар турында мәгълүмат кертү | «ККЭ ББЧ» ДМСна планлаштырыла һәм үткәрелә торган профилактик чаралар турында мәгълүмат кертү – 100 процент | ай саен | төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы контроль (күзәтчелек) органнары, Россия Федерациясе субъектларына гамәлгә ашыру вәкаләтләре тапшырылган федераль дәүләт контролен |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы контроль (күзәтчелек) органнары |
| 5.5. | «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча мәгълүмат системаларының мәгълүмати үзара бәйләнешендә контроль (күзәтчелек) органнарының гражданнар һәм юридик затлар белән үзара хезмәттәшлеге функцияләрен тәэмин итү | дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча мәгълүмат системаларының мәгълүмати үзара бәйләнеше; мәгълүмат системаларының үзара мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү, электрон формада дәүләт функцияләрен һәм муниципаль функцияләрне (шул исәптән «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша) башкару өчен кулланыла торган инфраструктура ярдәмендә контрольдә тотылучы затларга контроль (күзәтчелек) органының вазифаи затлары һәм башка вәкаләтле затлары тарафыннан кылына торган гамәлләр һәм кабул ителә торган карарлар турында мәгълүмат бирү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы контроль (күзәтчелек) органнары, Россия Федерациясе субъектларына вәкаләтләре тапшырылган федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы контроль (күзәтчелек) органнары». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларындагы мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм кулланылышын бәяләү, шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 19 февраль, 142 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 декабрь, 1335 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларындагы мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм кулланылышын бәяләү, шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләү тәртибендә, 1.1 пункттагы

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин